| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КУДАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КОДАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.04.2022 Кодаш авылы № 9

«Муниципаль хезмәткәрләрнең стажын исәпләү (яңадан исәпләү) комиссиясе турында Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2011 елның 28 июнендәге 10 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге Башкарма комитетының муниципаль норматив хокукый актларын Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Муниципаль хезмәткәрләр стажын исәпләү (яңадан исәпләү) комиссиясе турында Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2011 елның 28 июнендәге 10 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырырга һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль берәмлекләре порталы составында https://agryz.tatarstan.ru веб-адрес буенча мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарны үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе Ф.М.ШАКИРОВ